**ВЕБИНАР** «Игровая деятельность как средство развития речи детей раннего возраста на родном языке».

**Дата 20.10.18, время 13.00-14.00**

**Ведущий вебинара:** Амирова Гульсияр Раисовна, специалист консультационного центра «ПРОФЕССИЯ-РОДИТЕЛИ!», старший воспитатель высшей квалификационной категории МАДОУ «Детский сад № 95 «Балкыш»

Невозможно переоценить роль родного языка, который помогает людям, прежде всего детям, осознанно воспринимать окружающий мир и является средствами общения. Именно в раннем возрасте нужно обогащать словарь ребенка, приучать его самостоятельно пользоваться словами, стимулировать речевую активность и познавательные процессы через игровую деятельность.

**Цель.** Развитие речевой активности и коммуникативных способностей детей раннего возраста через игровую деятельность.

**Актуальность вебинара** объясняется необходимостью организации эффекивного взаимодействия семьи в игровой деятельности.

**Вопросы для обсуждения.**

- Основные этапы развития речи детей от года до трех лет через игровую деятельность.
- Повышение речевой активности, активизация словаря детей через игру.
- Развитие воображения и творческих способностей вместе с мамой
- Рекомендации по развитию речи детей раннего возраста на родном языке

**Вебинар предназначен** для родителей детей раннего возраста, воспитателям**,** старшим воспитателям, педагогам-психологам, руководителям и специалистам ДОО.

**Формат.** Онлайн

**Форма работы.** Мини-лекции, веб-презентация, групповое обсуждение.

**Уеннар аша ана телендә сөйләм телен үстерү.**

1. Ата-ананың төп бурычы балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү.

Алар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Шулар арасында иң әһәмиятлесе – уеннар. Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше.

Уен балаларны кызыксындыра, иҗатын үстерә. Җитез, өлгер, зирәк булып үсәргә ярдәм итә. Уен вакытында баланың сөйләм теле үсә, сүз байлыгы активлаша. Уен вакытында берүк сүзне күп тапкырлар ишетеп баланың сөйләм теле байый, камильләшә.Уенның нindиләре генә юк? Сүзле, дидактик уеннар, хәрәкәтле, рольле – сюжетлы һәм әлбәттә халкыбызның милли татар халык уеннары.

Татар телен өйрәтүче тәрбияче өчен уен – балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы да. Чөнки уен вакытында баланың сәләтен, барлык мөмкинлекләрен яхшырак күреп була.

Кече балалар өчен кирәк-яраклар, төрле җиһазлар, кулланмалар алдан ук әзерләп куела. Мәсәлән кулланыла торган уенчыклар, муляжлар, рәсемнәр, компьютер биремнәре, видео- аудиоязмалар. Аларның төрле һәм ачык төстә булуы ихтимал. Балалар уен барышында әлеге әсбапларны үз күзләре белән күрәләр, тотып карыйлар, үзләре катнашып уйныйлар. Бу үз чиратында сүзләрне, төсләрне истә калдырырга ярдәм итә, балаларны

активлаштыра, өйрәнелә торган материалга кызыксыну уята. Балаларның татар телендә сөйләм телләрен үстерә.

Кече яшьтәге балалар индивидуаль, парлы, группалы, коллектив уеннарда кулланыла. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, әгәр беренче уен татар бию көенә сикереп, йөгереп, биеп башкарылса; икенче уен тыныч мохиттә урыннарда башкарылса отышлы.

Балалар белән яратып уйналына торган татар халык уеннары: «Түбәтәй», «Кәрия – Зәкәрия», «Мияу – мияу нинди төс», «Ак калач», «Яулык салыш», «Чума үрдәк, чума каз», «Төймә җыябыз», «Очты, очты», «Бармак», «Миңлебай», «Йөзек салыш» һ.б.

Дидактик уеннар: «Чынаякның парын тап», «Әбием сандыгы», «Яфраклар», «Чәчәкләр», «Кар бөртекләре җыю», «Әйе, юк», «Нәрсә юк?», «Зур-кечкенә», һ.б.

Шулай ук өстәл һәм бармак театрлары уйнау балаларга кызыклы, төрле курчаклар аларны җанландырып җибәрә. «Бу бармак бабай», «Бу бармак кыяр», «Бу бармак груша», «Бармак, бармак кайда булдың?», «Баш бармагым туп була»,

Татар телендә уеннар уйнау балаларны саф татарча аралашуда кулланырлык итеп сөйләшергә этәрә. Татар теленә кызыксыну уята.

2. Балаларга татар телен өйрәтүдә минем төп максатым – балаларны

татарча аралашырга, сөйләшергә өйрәтү. Балалар күңелендә телебезгә, гореф- гадәтләребезгә, халкыбызга хөрмәт тәрбияләү, тарихыбызны югалтмау.

Балаларга телне өйрәтүгә, активлаштыруга милли татар халык уеннарын куллану гына түгел, ә заманча технологияләр, ягъни компьютер программаларын, тел өйрәтүче мультфильмнар, лэпбуклар кертү дә уңышлы нәтиҗә бирә. Компьютер биремнәре, мультфильмнар, лепбуклар балаларда уңай тәэсир калдыра, тел өйрәнүгә мотивация тудыра. Шөгыль барышында балаларны активлаштыра, мөстәкыйльлекне арттыра. Мондый шөгыльләр мавыктыргыч һәм файдалы уза. Тәрбиячегә шөгыльгә бирелгән вакытны дөрес һәм кызыклы үткәрергә ярдәм итә. Шуңа күрә шөгыльләрдә УМКна кертелгән мульфильмнарны, рәсемнәрне, татар җырлары, көйләре, әкиятләре язылган дисклар, интернет челтәреннән, лепбуклар файдаланам. Шулай да шөгыльләрне мавыктыргыч һәм кызыклы үткәрергә әлеге әсбаплар гына җитми. Шул рәвешле шөгыльләрдә өстәмә үзем эшләгән иллюстрацияле презентацияләр, фотослайдлар карточкалар, пиктограммалар да кулланам.

Бүгенге көндә мультимедиа технологияләре арасында презентацияләр, тел өйрәтүче мульфильмнар балаларның белем дәрәҗәсен арттыруда уңай ысул дип саныйм. Шөгыльләрдә балаларны тагы да мавыктыру, татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру максатыннан презентацияләргә, еш мөрәҗәгать итәм. Алар балаларга фикерләрен тупларга, материалны истә калдырырга ярдәм итә. Телне кызыксынып өйрәнергә этәргеч бирә. Балага информация төрле кызыклы формада җиткерелә. Мәсәлән, таблица, схема, карта, рәсем, фото, тавыш, анимация һәм башкалар.

Презентацияләрне шөгыльнең берничә этабында яки тулысынча шөгыль буе терәк формасында кулланам. Мәсәлән, «Ашамлыклар» темасын үткәндә, тиз уен формасында балалар белән сүзләр кабатлыйм. Экранда «Ничек әйтерсең?» уены. Диана, компотка нәрсә кирәк? Марат, син нәрсә яратасың? Слайдта төрле ризык рәсемнәре чыга. Бала шулар арасыннан дөресен сайлап ала.. Нәтиҗәдә, әлеге рәсемнәр ярдәмендә балалар ашамлык исемнәрен әйтәләр, үрнәк буенча үзләре 2-3 сүзлек җөмләләр төзиләр.

Презентацияләрне балаларда татар халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү максатыннан куллану да отышлы. Мәсәлән, экранда «Түбәтәй» уены чыгу белән балалар түгәрәк уенга чыгалар. «Түбәтәй» уенына биремнәр слайдта күрсәтелә. Татар бию көе

уйный, балалар түбәтәйне бер- берсенә тапшыралар. Көй туктагач, түбәтәй кигән бала экрандагы рәсемгә карап нәрсә икәнен төсен формасын, ничәү булуын әйтәләр.

Гомумән, әлеге заманча алымнар материалның диапозонын, белем бирүнең сыйфатын арттыра. Баланың сөйләм телен, татар телендә аралашырга мотивациясен үстерә. Татар теле шөгыльләренә кызыксыну уята.

3. Уен эшчәнлеге- мәктәпкәчә яшьтәге бала үсешендә зур этәргеч

балалар өчен уен тирәлеген булдыру мөһим шарт булып тора. Мәктәпкәчә яшь чорындагы уеннар эчтәлегеннән чыгып, уеннарның берничә төрен күрсәтергә була. Аларның үзләренә генә хас атрибутлары, уен кирәк-яраклары була.

Күпсанлы тикшеренүләр һәм күзәтүләр кул бармаклары хәрәкәтләре үсеше дәрәҗәсенең сөйләм үсеше дәрәҗәсе белән туры килүен дәлиллиләр. Сөйләм үсеше җитлекмәгән күпчелек балаларда кул хәрәкәтләренең зәгыйфьлеге (төгәлсезлек) күзәтелә. Авазларны әйткәндәге кимчелекләр – балага начар тәэсир итә, ул эченә йомыла, кырыслана, тынгысызга әверелә, аның кызыксынучанлыгы кими. Баланың телен ачуда, сөйләмен формалаштыруда бармак уеннары аерым урын алып тора. Бармак күнегүләре һәм бармаклар белән ритмик хәрәкәтләр ясау баш миенең сөйләм өчен җавап бирүче өлкәсенең ярсынуына һәм сөйләм зоналары эшчәнлеге көчәюгә китерә. Нәтиҗәдә сөйләм усешеннә уңай тәэсир ясала.

Бармак уеннары – өлкәннәр белән балаларның үзенчәлекле аралашу, күңел ачу чарасы. Бишек җырлары баланы тынычландыру, юату өчен кулланылса, бармак уеннары, киресенчә, баланың күңелен күтәрү, кәефен яхшырту, көлдерү чарасы булып тора. Ул баланың бармак хәрәкәтләре үсешенә дә ярдәм итә. Балаларның психикасын өйрәнүче галимнәр "бармак хәрәкәтләре үсеше нормада була" дип саныйлар.Димәк, бармакларның сөйләм үсешенә дә тәэсире зур. Бармаклар белән төрле күнегүләр ясау, аларны төрлечә хәрәкәтләндерү – баланың сөйләмен үстерүдә уңай шарт булып тора.

Кул чуклары өчен күнегүләр ясатканда нәниләрнең яшь үзенчәлекләрен истән чыгарырга ярамый. Гадирәк уеннардан башларга кирәк. Мәсәлән, "Күрешү" уены. Бу уен бармакларның исемнәрен хәтердә калдырырга да ярдәм итә. Баш бармакның очы имән бармакка тидерелә. "Исәнме, имән бармак" һәм шулай итеп баш бармак калган барлык бармаклар белән исәнләшеп чыга.

Бармак моторикасын ныгыту өчен үз эшемдә бармак уеннарына аеруча зур игътибар бирәм. Түбәндә балалар Зулана торган бармак уеннары тәкъдим итәм.

1. Без кәбестә турыйбыз, (бармак чуклары белән кисү хәрәкәтләре ясау)
Кишерен дә уабыз, ( кулны йодрыклап, уу хәрәкәтләре ясау)
Тозларны да сибәбез, (тоз сибү хәрәкәте)
Кәбестәне кысабыз. ( учларны йодрыклау һәм ачу хәрәкәтләре)

2. Карга килде – казан асты,
Торна килде – тоз салды,
Саескан килде – салма салды
Күгәрчен килде – куп ашады,
Аккош килде – туймый калды,
Кетер-кетер, казан төбен кимерер.

3. Биек нарат астында куркак куян утыра ( бер кул – "нарат"(кул чугы өскә караган, бармаклары аерылып тора), икенче кул – "куян" (имән һәм урта бармаклар –"куян колагы", ә калган бармаклар кысылып тотыла)

4. Бармакларны эләктерәбез,
Терсәкләрне күтәәбез,
Килеп чукты чыршы,

Сөендереп безне. (кулларны эләктереп тотырга, уч төпләре бер-берсенә почмак астында, бармакларны алга чыгарырга, терсәкләрне гәүдәгә терәмәскә).

5. Кәҗәкәй. Әлеге уенны бала өлкәннәр сөйләмен аңлый башлагач ук уйный башлый. Кул "кәҗә" ролен башкара. Учны аска таба каратып бармаклар йодрыклана, ә баш бармак белән чәнчә бармак алга таба сузыла. Бу вакытта түбәндәге шигырь юллары әйтелә:

Кәҗ, кәҗ, кәҗәкәй,
Минем улым (кызым) бәләкәй,
Ул – акыллы, ул – тәтәй,
Тимә аңа, кәҗәкәй!

Соңгы сүз әйтелгәч, бармаклары бөгелгән "кәҗә" "Сөзәм, сөзәм, сөзәм!" — дип, бала тәненең кайсы да булса бер өлешен җиңелчә генә кытыклый. Бала чыркылдап көлә.

6. Туп. Түгәрәкләндерелгән уч төпләре туп рәвешендә бер-берсе белән тоташа. Бер бала "тубын" икенче баланың кул өстенә куя. Алар кара-каршы басып, "туп" чөеп уйныйлар:

Рөстәм, сиңа туп бирәм,
Әйдә, уйныйбыз бергә,
Кирәк аны, чөеп-чөеп,
Тотып ала белергә.

7. Песием, песием… Бер бала икенче балага кул сыртын сузып тора. Икенчесе: "Песием, песием, песием" дия-дия, аның кул аркасын сыйпый да кинәт; "Прес-с!" дип, җиңелчә генә аның кулына сугып ала. Бу вакытта бала тиз генә кулын тартып алып өлгерергә гиеш. Әгәр кулын алып өлгерсә, ул — җиңүче, өлгермәсә — отылган була. Рольләр алмашына һәм уен дәвам итә.

Ясалган күнегүләр кул чугы һәм бармаклар ныгуга китерә, ә бу үз чиратында киләчәктә язу күнекмәләрен җиңелерәк үзләштерергә ярдәм итә. Шуны истән чыгармаска кирәк: вак моториканы ныгытуга файдалы булсын өчен, бармак уеннары һәрвакытта да чиратлап ике кул белән кабатлана.

4. Һәр милләтнең педагогикасы нигезендә шул милләтнең теле һәм

әдәбияты ята. Бала фәкать ана телендә генә дөньяны бөтен нечкәлекләре белән танып – белә ала. Димәк, ана телен бөтен нечкәлекләре белән үзләштерү халык авыз иҗатын уңышлы куллануга туры юл.

Тел кешенең нинди милләткә караганын күрсәтә торган төп сыйфат. Гадәттә, кеше бөтен нечкәлекләре белән ана телен генә бик яхшы белә. Чөнки баланың теле ана теле белән ачыла, ул бу телне бик яшьтән үзләштерә һәм бу процесс бик гадәти шартларда уза. Халык авыз иҗаты һәрбер халыкның мәдәни байлыгын чагылдыра.

Халкыбыз авыз иҗаты әсәрләре – яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак. Халыкның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы әкиятләре, киң колачлы җырлары, тирән фәлсәфи әйтемнәре, тапкыр һәм үткер мәкальләре, үзенчәлекле табышмаклары, яшьләргә сабак бирердәй итеп иҗат ителгән риваять, дастан, легендалары һәм башка күп төрле иҗат җимешләре киләчәк буынны милләт тормышын дәвам итәрлек, аны үстерүгә өлеш кертерлек итеп тәрбияләүдә, сөйләмнәрен үстерүдә зур рухи чишмә, чыганак булып тора.

Балаларның тел байлыклыкларын үстерүдә аларга әниләренең сөйләгән әкиятләре, бишек җырлары зур әһәмияткә ия. Аналар балалар белән әле аларның телләре ачылганчы ук сөйләшә башлыйлар. Моның әһәмияте шунда балалар әниләренә охшарга тырышалар, сүзләрне отып калып уеннарда кулланалар.

*Бишек җырлары* - кеше күңеленең иң нечкә кыллары. Ул җырлар газиз ана, туган тел, туган ил кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри. Бу табигый да, чөнки бала шигъри матурлык, анарарның йөрәк җылысы, үз халкының поэтик рухы белән тәүге кат шушы

җырларда очраша. Бишек җырлары ана белән бала икәүдән – икәү генә калган вакытта башкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй – фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп җиткерергә омтыла. Бишек җырлары балалар бакчаларында баланың сөйләмен баетудакулланып була. Курчак уеннары вакытында балалар тарафыннан бишек җырлары көйләнгәндә уен тагын да кызыклырак килеп чыга.

*Әкиятләр* - балалар арасында иң популяр әсәрләр. Моның сәбәбе - әкиятләрнең гаҗәеп оста иҗат ителгән, формасы эчтәлегенә тәңгәл килгән булуында һәм әкият табигатенең балалар табигатенә бик якын торуында. Татар халкы әкиятләргә бай халык. Ул иҗат иткән әкиятләр эчтәлек һәм формалары ягыннан өч төргә бүленә: хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы әкиятләр, тормыш – көнкүреш әкиятләре. Әкиятләр нәниләрнең рухи үсешендә әхлагын төзәтүдә, туган телен камилләштерүдә зур роль уйный.

*Эндәшләр.* Балалар фольклорында бу әсәрләр табигать көчләренә: яңгыр, кояш, җилгә,һ.б. эндәшүләр рәвешендә яши. Аларның үзләренең чыгышы белән халкыбызның борынгы йолаларына (“Карга боткасы”, “Нәүрүз” һ.б.) барып тоташа. Йола бәйрәмнәрендә кешеләр мәрхәмәт, муллык сорап кояшка, яңгырга мөрәҗәгать иткәннәр. Заманалар узып, йолалар онытылгач, бу мөрәҗәгатьләр матур яңгырашлы мавыктыргыч булулары белән балаларның игътибарын җәлеп иткән һәм буынга буынга күчеп хәзергәчә сакланып калган.

*Әйтенүләр*. Төрле бөҗәкләр, кош кортлар белән уйнау, алар белән “сөйләшү” балаларга зур ләззәт бирә.

*Әйтешләр*. Балалар телендә диалог формасында төзелгән шигъри әсәрләр аерым бер төркем тәшкил итә. Бу әсәрләрне кара-каршы яки бер генә бала башкара ала. Аларны әйтешләр дип атыйлар. Бу әсәрләр, гадәттә, сузынкы, салмак бер көйгә әйтелә һәм балаларның сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерүдә ярдәм итә.

*Такмаклар.* Бию вакытында, күңел ачканда җырлап яисә ритм белән әйтелә торган әсәрләрне такмаклар дип атай кабул ителгән. Алар өч тармакка бүленә: бию такмаклары, көйләм такмаклары, сөйләм такмаклары. Такмакларның тәрбияви һәм сөйләмне камилләштерүдә әһәмияте зур.

*Такмазалар*. Балалар телендә күңел күтәрү өчен сөйләнә торган шигъри әсәрләрнең бер өлешен такмазалар тәшкил итә. Такмаклардан аермалы буларак, такмазаларда шигъри үлчәм даими түгел, үзгәреп тора. Аларны рифмаларга нигезләнгән ирекле сөйләм шигыре дип атарага мөмкин.

*Тел көрмәкләндергечләр*. Балаларның сүзләр белән уйнауга омтылышы тел көрмәкләндергечләрдә бигрәк тә ачык күренә. Тел көрмәкләндергечләрнең бөтен хасияте аларның авыр әйтелешендә. Бу әсәрләрдә авыр әйтелеш төрле алымнар оештырыла һәм сөйләмнең һәр сүзе билгеле бер аваздан башлана. Тел көрмәкләндергечләр халык тарафыннан иҗат ителгән тел төзәтү (логопедик) чаралары алар. Балаларның телен ачтыру, авазларны дөрес әйтергә өйрәтүдә әлеге әсәрләрнең әһәмияте бик зур.

*Санамышлар.* Кайбер уеннарда балаларга башлап йөрүче , төп персонажны сайлап куярга кирәк. Бер бала һәр уенчыга бармагы белән төртеп ритмлы шигъри сөйләм белән санап төп рольне үтәүчене билгели. Бу вакытта әйтелә торган шигъри текстларны санамыш дип йөртәләр. Санамышлар күп төрле. Кайберләре гади саннарга корылып иҗат ителә, кайберләренә исә сюжетлылык хас.

*Мәкаль*. Мәкаль дип телдән – телгә күчеп йөрүче, халыкның зур тәҗрибәсен туплаган дидактик эчтәлекле, кыска образлы сөйләмнәргә әйтәләр. Татар халык авыз иҗатында мәкальләр шактый зур урын алган, тормышта нык таралган һәм киң кулланыла торган жанр исәпләнә.

Мәкальләрнең тормыштагы ролен балаларга аңлатып бирү тәрбияви яктан бик файдалы. Аларны өйрәнү, хәтердә калдыру, урынлы файдалана белү сөйләмне баета, эзлекле фикерләүне үстерә, камилләштерә, халыкка, туган телебезгә мәхәббәт, гүзәл сыйфатлар тәрбияли.

*Табышмаклар* балаларга өстәмә мәгълүмат биреп, тормышны танып белергә өйрәтеп кенә калмый, балаларда игътибарлылык, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияли, аларның эзлекле һәм образлы фикерләү сәләтен үстерүгә булыша, тел байлыгын арттыра, туган телгә мәхәббәт тәрбияли

*Уеннар.* Балаларның рухи яктан бай, физик яктан сау – сәләмәт булып үсүендә уеннарның әһәмияте бик зур. Олыларга эштән бушаган вакытларда күңел ачу, ял итү, вакыт уздыру өчен бер чара булса, бала өчен уен – чын шөгыльгә, тормыш көрәшенә һәм хезмәткә әзерләнү ул. Нәниләрнең уеннары асылда зурларның тормышы, көнкүреше һәм хезмәтенең бер чагылышы булып тора.

Халык авыз иҗаты әсәрләре гасырлар дәвамында тупланып килгән олы поэтик һәм педагогик мирас ул, балалар күңелендә туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тернәкләнә. Нәни чакта сөйләнгән шигъри әсәрләр бөтен гомер буена кеше күңелендә кала һәм буыннан буынга тапшырыла.

**6. Бала кечкенә чакта ук өйдә нәрсә эшләргә?**

*Мәгълүмат "Гаилә һәм мәктәп" журналыннан алынды.*

Әле бала кечкенә чакта ук аның белән бергәләп китап укырга, рәсемнәр карарга кирәклеген һәркем белә. Тик моның үз тәртибе бар. Һәр рәсемне аңлатып, сабый өчен үзегез сөйләргә ашыкмагыз. Сораулар биреп, аны сөйләтергә тырышыгыз.

Әйтик, китаптагы берәр сурәткә күрсәтеп, аның кем булуы, нишләве турында кызыксыныгыз. Улыгыз яки кызыгыз геройның кигән киеме, кәефе турында да әйтсен. Сабый өчен биремне катлауландырырга мөмкин. Балагыз герой ишетергә, тоярга мөмкин булган авазлар, исләрне күз алдына китереп карасын. Рәсемдә нинди дер ризык сүрәтләнгән икән, аның тәме нинди булырга мөмкинлеген әйтсен.

Бераз үскәч, бала, рәсемдә күргәннәрне генә сөйләп калмыйча, аңа кадәр ни булуын, моннан соң нәрсә буласын да аңлата башларга мөмкин.

Мисал өчен, рәсемдә бер әбинең таганда атынып утыруы сүрәтләнгән ди. Аның янына балалар тезелешкән. Бу рәсем нәрсә турында сөйли? Нигә таганда балалар түгел, әбт атына? Балачагын исенә төшерегә теләгәнме ул? Әллә инде автобуста үзенә урын бирмәгән малайларга үч итеп, таганга хуҗа булып алган да, алаларга атырга бирмиме? Ахыр чиктә әби таганнан төшеп, аны балаларга калдырырмы? Малайлар нәрсә дияр?

Балага хыялланырга, үз фикерен булдырырга менә дигән мөмкинлек бу!

**Әти-әниләр өчен рәсем-сурәтләр белән эшләү юллары:**

- Балага, рәсемгә карап, моңа кадәр ншрсш булуын, моннан соң ни буласын уйлап табарга тәкъдим итү;
- төп герой яки предметны башкасына алыштырып карау (әйтик, таганда әби түгел, ә полиция хезмәткәре атынса, сюжет ничек үзгәрер иде);
- вакыйгалар урынын үзгәртү (мәсәлән, әби белән балалар автобуста очраша ди).

Бала рәсем буенча сөйләргә өйрәнгәч, үзенә хикәя төзетә башларга да була. Баланың иҗат итү теләген арттыру өчен анаң "әсәрләрен" язып барып, туганнарыгызга, дусларыгызга укый аласыз.

Тик шунысын истән чыгармагыз: хикәяне матурлыйм дип, бала әйткән сүзләрне башкасына алаштырырга ярамый! Әгәр сабыегызның иҗат җимешендә кайсыдыр сүз күңелегезгә ятып бетми, аны әдәби канунннарга туры китерәсегез килә икән, бу хакта балгыз белән уртага

салып сөйләшегез. Сабыегызның фикерен башкача ничек әйтеп булыр иде – бу турыда да үз киңәшегезне бирегез.

Баланың яшенә һәм әзерлегенә карап, иҗади хикәя төзү буенча биремнәр дә үзгәрә. Кечкенәләр өчен олы кеше вакыйганың төп өлешен сөйләп бирә,сабый исә аның чишелешен генә уйлый. Мәсәлән, өлкән кеше балага болай дип сөйли башлый: “Әминә исемле кыз елап басып тора.Чөнки ул урамда уйнаган вакытта бияләен югалта... “Сабый исә, әлеге вакыйганы дәвам итеп: “хәзер аның куллары туңа.Шуңа күрә ул кире өенә кайта”,-диярга мөмкин.

Бала теге яки бу вакыйганы яхшырак күз алдына китерә алсын өчен, аның тормыштан алынган булуы мөһим.

Икенче этап буларак, балага план буенча хикәя төзергә куша аласыз. “Башта Әминәнең әнисе белән кибеткә барырга әзерләнүэн сөйлә. Юлда ниләр күрә? Кибеттә нинди кызыклы хәл була?” – дип, улыгыз яки кызыгызга юнәлеш бирегез. Балалар белән әкияти хикәяләр дә төзергә мөмкин. Мәсәлән, “Убырлы карчыкның шәһәрдә күргәннәре”. Бу очракта бала фантазиясен эшкә җигәчәк.

Соңарак, биремне катлауландырып, балага хикәянең темасын гына әйтәсез. Ә ул вакыйгалар бәйләнешен, сюжетны үзе уйлап таба.

Балагызның иҗат җимешләрен бергә туплап, кечкенә генә китапчык ясарга онытмагыз. Ә ул мавыктыргыч хикәяләрен рәсемнәр белән бизәсен. Бу китапчык әби-бабайга, апа-абыйга төрле бәйрәмнәр уңаеннан менә дигән бүләк булачак, ә баланы исә яңа иҗат эшләренә рухландырачак.